МИНИСТЕРСТВО СПОРТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.12.2024

Казан шәһәре № 593

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2023 елның 12 сентябреннән 439 нчы номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы комиссиясен төзү турында» (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2024 елның 21 июненнән 318 нче номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы комиссиясе (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторы мөдире Зарипова Мәдинә Абдулла кызын комиссия составыннан чыгарырга.;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторының әйдәп баручы консультанты Игнатьева Алсу Җәүдәт кызын комиссия составына кертергә, аны комиссия секретаре итеп билгеләргә;

Сәлахова Гүзәл Марсель кызының вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторы мөдире».

Министр В.А. Леонов